Мөслим гимназиясе укучылары газетасы

МӨСЛИМ ГИМНАЗИЯСЕ

# ТЫЛСЫМ+

№4 (36) Февраль, 2020 нче ел

Бу санда


Әтиемнең абыйсы – Әфган сугышы ветераны 2

Фронт юлларын узган бабам – безнең горурлык 3

Муса Җәлил безнең йөрәкләрдә 4

75 ел Бөек Җиңүгә 4


## ГИМНАЗИЯ СУЛЫШЫ

### Гимназия - яшь патриотлар территориясе




Бөек Җиңүнең 75 еллыгына багышланган “Тормыш дәресләре” ндә сугыш һәм тыл ветераннары катнашты.

Хәрби-патриотик айлык кысаларында гимназиядә сугыш техникалары макетлары күргәзмәсе оештырылды. 1-7 нче сыйныф укучылары төрле материаллардан үз эшләнмәләрен тәкъдим иттеләр.

“Мөслим очкыннары” муниципаль проекты кысаларында 8 нче сыйныф укучылары “Бизнес-проект” башкара. 9 майга кадәр алар георгий ленталары ярдәмендә бәйрәм символикасы ясыйлар.

### “Кеше тәрбияләү - 2020” республика бәйгесе җиңүчесен котлыйбыз!



Тәрбия эшләре буенча директор урынбасарлары “Кеше тәрбияләү” конкурсының муниципаль этабында гимназия завучы Ямалова Гөлнара Фердинант кызы 8 нче а сыйныфында “Конфликт. Аны ничек чишәргә?” темасына тәрбия дәресе күрсәтте. Аның чыгышы беренче урынга лаек дип табылды.

### Гимназия – интеллектуаль үсеш мәйданчыгы







“Интеллект. Культура. Карьера” республикакүләм проект-тикшеренү конференциясендә катнашып, 5 нче б сыйныфы укучысы Кашапов Данияр инглиз теле, 7 нче а сыйныфы укучысы Бәдертдинова Әдилә рус теле буенча III дәрәҗә Диплом белән бүләкләнделәр.

“Тере классика” әдәби конкурсының муниципаль этабы старт алды. Башлангыч сыйныф укучылары Бурганова Карина (4а) - 1 урын, Закиров Искәндәр (1б) - 2 нче урын яулады. Садриева Рәзилә(4б), Антонова Виктория (3а), Хафизов Әмир (2а) төрле номинация җиңүчеләре булды.

Югары сыйныфлар арасында 9 нчы б сыйныфы укучысы Харитонова Рената - 1 нче урынга лаек дип табылды. 6 нчы сыйныф укучылары Шәймәхәммәтова Миләүшә, Галиева Сөмбел, Филиппова Майя, 7 нче сыйныфтан Идиятуллина Сабина, Бәдертдинова Әдилә, Биккинина Наилә (5б), Шәрифуллина Алсу (8а), Исламгалина Алина (9б) торле номинацияләрдә җиңүче булдылар.

### Гимназия – спорт һәм сәламәт яшәү рәвеше территориясе




“Чаңгы юлы - 2020” ярышларында Мөслим гимназиясе коллективы җиңүче дип табылды. Иң актив гаиләләргә кинотеатрга бару мөмкинлеге бирүче сертификатлар тапшырылды.

Укытучылар спортта сынатмый. Оешма-предприятиеләрнең XXX Кышкы спартакиада уеннарында милли көрәш, волейбол, баскетбол, канат тарту, шахмат, бадминтон, өстәл теннисы, мини-футбол, армрестлинг, йөзү буенча көч сынашалар. Алга, яңа үрләргә!

# СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ ГЕРОЙЛАРЫ БЕЛӘН ӘҢГӘМӘЛӘР

## Әтиемнең абыйсы – Әфган сугышы ветераны

*Симәк егете, минем әтиемнең абыйсы Данил Госмановның мәктәптән соң Әлмәт төзүчеләр техникумында укып йөргән көннәре. Беренче курсны тәмамларга да күп калмый. 1987 нче елның 4 маенда аның кулына армиягә повестка тоттыралар. Солдат вещмешогын иңенә аскан егетләрне “Вам повезло” дип озатып калган майор ни әйтергә теләде икән? Сигез елга якын исеме үк солдат аналарының йөрәген көйдергән әфган утына китәселәрен белеп, егетләрне борчымаска булганмы? Барып җиткәч, үзләре дә аңлар, әлегә тыныч булсыннар, дип уйлаганмы?*



**Данил абый, армия хезмәтен Әфганстан җирендә үтү хәбәрен ничек кабул иттегез?**

– Күңелдә курку хисе бар иде. Ләкин нидер уйлап торырга җай булмады. 16 майда Казанга килеп төштек, өч сәгатьтән безне Пензага алып та киттеләр. Ә анда җиде кат иләк аша үткәрделәр. Бер көндә 7 тапкыр рентген гына тордым! Уйлыйм да, исем китә...

Эшелонга төялеп, көчле сак астында Үзбәкстанның Термез шәһәрендәге хәрби частькә барып җиткәч кенә “Хезмәт итү урыны – Әфганстан” дигән язу, 2 км ераклыкта гына күренеп торган әфган таулары икеләнүләргә нокта куйды.

*Данил абыйны 3 нче артиллерия батареясенең 3 нче взводында “2С-1” үзйөрешле артиллерия установкасына наводчик (көйләүче) итеп билгелиләр. Биш айга сузылган өйрәнүләр – 15әр километрга марш-бросоклар, полигонда артиллериядән атулар, мораль-психологик яктан әзерләүләр...*

**Шулай да, сезнең өчен иң авыры нәрсә булды?**

– Иң авыры климатка өйрәнү булды. 40-50 градуска җиткән кайнарлык, сусызлык үзәккә үтте. Кайнамаган су эчәргә ярамый. Күпме саклансам да, сары чире эләктереп, тернәкләндерү үзәгендә ятып чыгарга туры килде.




**Хәтерегездә уелып калган берәр вакыйга турында сөйләгез әле.**

- 1987 нче елның 4 ноябре. Тулы хәрби әзерлек белән Кандагарга очу. Аннан – Әфганстанның көньяк өлешендәге Регистан чүлендәге хәрби ноктага. Дошман белән беренче бәрелеш. 4 декабрь көнне кышлак ягыннан, миналанган чүл буйлап, берни булмагандай өч ишәк килеп чыкты. Көндезен ул-бу булмаса да, төштән соң, әллә шул ишәкләр аркасында, дошман безнең солдатларны реактив ракеталар яңгыры астында калдырды. “К бою!” дигән команданы ишетсәк тә, без, яңа килгән солдатлар, бер мәлгә югалып калдык, саклану инстинкты да формалашмаган әле. Шунда “дед”лар ярдәмгә килде: кайсы, сине гәүдәсе белән каплап, өстеңә ава, кайсы окопка сөйри. Ничек итсәләр итәләр, батарея гаубицадан ут ача. Дошман тына. Теге ишәкләр “сын полка”га әйләнде. Аларны ашаттык, читкә җибәрмәдек. Файдалары да тия: ишәкләр белән снарядлар, башка сугыш кирәк-яраклары ташыйбыз. Әкренләп кинәт башланган атышларга да өйрәнә башладык.

*Данил Госмановның расчеты батареяда атна саен оештырылган ярышларда гел беренчелекне ала. Җитезлек тә бар, физик әзерлекләре дә яхшы, бер атуда “цель”не дә юк итәләр. Тырышлыкның “файдасы” – боларның расчетыннан ике егетне башкаларга кушалар. Биш кеше урынына нибары өчәү калалар. Орудие командиры – Украинадан Владимир Сидляр, коручы – Кабардино-Балкариядән Ахмед Дзугулов һәм көйләүче – Мөслим егете Данил Госманов. Интернациональ сугышчылар сынатмый. Союздан килгән колонналарны артиллерия белән “Нагахан борылышы”, “Черная площадь”, “Элеватор” дигән куркыныч җирләрдән Кандагарга кадәр озату буенча хәрби операцияләрне дә уңышлы башкаралар.*

**Сугыш авырлыклары төшегезгә кереп борчымыймы?**

– Андагы бөтен авырлыкка да түзәргә өйрәндек, алар күптән онытылды да кебек. Әмма иптәшләрнең үлеме генә һаман да йөрәкләрне тетрәндерә. Күрше дус халыкка интернациональ ярдәм күрсәтәбез дип, 18-20 яшьлек күпме егетләрнең гомерләре өзелде.

*Данил Госманов хезмәт иткән 3 нче артиллерия батареясе Әфганстаннан 1989 нчы елның 15 февралендә чыгарыла. Хезмәт срогын Тамбовта тутырып, 24 майда туган авылына кайта, техникумда укуын дәвам итә. “Мин – әфганчы” дип, күкрәк киереп йөрми. Ике елдан соң диплом алырга сугышчан медальләрен тагып килгәч кенә беләләр араларында ут эченнән кайткан батыр егет булуын.*

*Авылларны газлаштыру еллары. Данил җиң сызганып эшкә тотына. Йортларга, социаль объектларга зәңгәр ягулык кертүдә тырыш хезмәтен куя. 1995 елдан башлап, бер үк вакытта район газ участогында слесарь хезмәтен дә башкара ул.*

**- Данил абый, сез бик тә аралашучан, вакыйгаларның үзәгендә кайныйсыз, актив тормыш алып барасыз. Әфган сугышында батырларча һәлак булган якташларыбызның туып үскән йортларына истәлек такталары куюда башлап йөрисез.**

- Әйе, миңа 2016 елда районның сугышчы-интернационалистлар иҗтимагый оешмасын җитәкләүне ышанып тапшырдылар. Шуннан бирле, локаль конфликтлар ветераннары белән тыгыз элемтәдә булып, алар белән төрле чаралар оештырабыз. Истәлек такталарының беренчесен үз акчама эшләттем. Укучылар белән очрашуларга йөрибез. Районда гына түгел, республика районнарында яшәүче әфганчылар белән ныклы элемтә урнаштырдык. Үзешчән сәнгатьтә катнашам. Бигрәк тә әфган турындагы җырларны бөтен күңелемне биреп башкарм.

Таш кыялар арасында башларын салган яшьтәшләрем алдында, аларның якыннары алдында үземне бурычлы хис итәм. Алар өчен дә яшим кебек.

***Ильвир Госманов,***
***7 нче а сыйныфы укучысы***

*Зиннур Галиев һәм Ленар Хөснетдинов белән әңгәмәне укый аласыз*

# БӨЕК ҖИҢҮНЕҢ 75 ЕЛЛЫГЫНА БАГЫШЛАНГАН СӘХИФӘ

## *Фронт юлларын узган бабам – безнең горурлык*



Җирдә яңа кеше туа һәм, якты дөнья белән исәнләшкәндәй, беренче тапкыр кычкырып аваз сала. Бәхетеннән чиксез шатланган ана, елмаеп, сабыена төбәлә һәм әкрен генә әлеге сүзләрне кабатлый: “Син дөньяга килдең, син бәхетле, илебезнең киләчәге синең кулда”.

Әйе, һәрбер ана үз сабыена сөенеп, зур өмет белән, ышанып карый. Чөнки ул аны үзенең киләчәген дәвам итүче, илнең тынычлыгын саклаучы итеп үстерә. Әгәр дә нәни баланың гөнаһсыз чиста күзләренә карап, аның кайчан да булса үз иленә, халкына кан-яшь алып килүче явыз җәллад, яисә кемгәдер бил бөгүче мескен кол булуы күз алдына килсә, аның бәхетле буласына ышанып идеме икән аналар?

Бәхетле бул, балам! Кайсы гына ана үз баласына бу изге теләкне теләмәде икән?! 1941 нче елның 22 нче июнь таңында Ватаныбызны фашист илбасарларыннан саклап калырга, аның азатлыгы, тынычлыгы өчен гомерләрен кызганмыйча көрәшергә ант иткән һәм антларын кайнар каннары белән үтәгән миллионнарча ир-егетләрнең, хатын-кызларның, ятим калган кайгылы балаларның газиз аналары да дөньяга килгән сабыйларына шушы теләкне теләгәннәрдер.

Минем әнием ягыннан ерак әбиемнең әтисе – карт бабам Саттаров Әхмәт Вәли улы да шушы рәхимсез сугышта катнашкан. Ул гаиләдән берүзе фронтка китә. Бабай ул вакытларда, мәктәпне тәмамлагач, Казанда ФЗОга (фабрично-заводское обучение) җибәрелгән була. Сугышның беренче көненнән яу кырына ашкынса да, яше җитмәгәнгә, аны тиз генә алмыйлар.

Шулай да, ул теләгенә ирешә. Бабайны 1942 нче елда сугышка алалар. Бу чорда Смоленск шәһәре тирәсендә көчле сугышлар барган. Ул сугышка пехота, ягъни җәяүле сугышчы булып керә. Көчле сугышларның берсендә Проня дигән елганы кичәргә тиеш булганнар. Елганың бер ярыннан икенче ярына тросс тарттырып, сал ясап, троссtotка тартылып, ике рота елганы кичә. Шунда алар бәхетсезлеккә очрыйлар: немецлар, су өстендәге хәрәкәтне сизеп алып, ут ачалар. Бабайдан 10 метр ераклыкта гына фашист солдаты күренә. Ул, шуышып килеп, граната ыргыта һәм бабайның аркасы яралана. Ул солдатны бабай шунда ук үтерә һәм ярдан сикерә. Бераз вакыт йөзгәннән соң, бабайның хәле бетә. Аның бәхетенә, елгада бүрәнә агып килә, һәм бабай шул бүрәнәгә тотынып, күпмедер хәл җыйганнан соң, ярның икенче ягына йөзеп чыга. Елга аркылы йөзеп чыккач, 150 кешедән 6 кеше генә исән калганы ачыклана. Алар арасында берсе взвод командиры һәм калганнары рядовой солдатлар була. Проня елгасы янында барган сугыш хәрәкәтләрендәге батырлыгы өчен, бабайны “Кызыл Йолдыз” ордены белән бүләклиләр.

Госпитальдә дәваланганнан соң, бабайны танк подразделениесенә җибәрәләр. Ул командир вазифасын башкара. Алар, дошманны эзәрлекләп, куып баралар. Елгаларны кичкәндә, танкларны чыгару өчен, пантон күперләре төзегәннәр. Белоруссиядә сазлыклы урыннар бик күп. Шуна күрә, танклар белән ул сазлыкларны урап үтәргә туры килгән. Польша җиреннән танк колоннасы белән барганда, кинәт кенә колоннаны туктаталар. Танкларыннан төшсәләр, фашистларның вәхшилегеннән өнсез калалар: 200 ләп җирле халыкны (хатын-кызлар, балалар, картлар) урманны аударган кебек атып үтергәннәр. Бу вакыйганы бабай бигрәк тә йөрәге әрнеп искә ала иде.

Бабай Смоленск, Могилев, Минск, Кинегсберг, Варшава, Потсдам шәһәрләрен азат итүдә катнаша.

Сугышчыларның буш вакытлары бик сирәк булган. Чөнки сугыш көне-төне тынып тормаган. Ә буш вакыт булды исә, якыннарына хат язганнар. Сугышчыларны ашатырга гаскәр артыннан зур котеллар таккан кыр кухнясы йөргән, өч көнлек коры паек запасы биргәннәр. Монда сохари, тушенка, консервалар булган.

Сугыш беткәч, бабайларны Кырым ярымутравына - Симферополь шәһәренә чыгаралар. Сугыш тәмамланып, ел ярым үткәч кенә өйгә кайтырга насыйп була.

Сугыш! Никадәр кайгы-хәсрәт, югалту, бәхетсезлек китердең син тынычлык халкына? Син аның бәхетен урлап, рухын сындырырга, юк итәргә, колга әйләндерергә, кешеләрне тезләндереп, алар өстеннән явызларча хакимлек итәргә теләгәнсеңдер. Безнең илнең көчсез, әле ныгып җитмәгән булуыннан файдаланырга теләгәнсеңдер. Ләкин бер хакыйкатьне син аңламагансың: безнең илебез яшь, көчсез булса да, аның горурланып сөйләрлек, курку белмәс, җиңелмәс батыр уллары, кызлары, шундый батыр йөрәкле балалар үстергән бөек аналары бар. Аларга бәхет төшенчәсе туганда ук, ана сөте белән керә, әнә шуны чын мәгънәсендә аңлау аларга бетмәс-төкәнмәс көч, туган илгә кайнар мәхәббәт бирә, әнә шул көч җиңүгә алып килә. Безнең илебез зур

> ***Бәхетле бул, балам! Кайсы гына ана үз баласына бу изге теләкне теләмәде икән?!***

сынаулар, авыр юллар, чиксез күп югалтулар белән җиңү таңын каршылады. Юк, җиңел генә бирелмәде безгә тынычлык, шуңа күрә дә без аның кадерен беләбез. Без бәхетле яшәсен өчен, егерме миллион кеше яу кырында ятып калган. Без алар алдында баш иябез, илебезнең киләчәге сезнең кебек үк ышанычлы кулларда, аның тынычлыгын һәрвакыт саклarбыз, изге туфрагыбызга вәхшиләрнең аягын да бастырмыйбыз, дип ант итәбез.

***Сабина Идиятуллина,***
***7 нче а сыйныфы укучысы***

*Теманың дәвамын укый аласыз*

********

## ТЫНЫЧЛЫК ТЕЛИМ

Зәңгәр күктә – ак болытлар,
Уйный кояш нурлары.
Алтын бодай башаклары
Дулкынлата кырларны.

Сокланабыз гүзәллеккә,
Барыбыз бер фикердә:
Тилмермәсен кеше ачка,
Сугыш булмасын җирдә.

Кара кайгы – сугыш җиле
Кермәсен илебезгә.
Аяк чалмасын бомбалар
Киләчәк көнебезгә!

***Солтанова Алия,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

# ГИМНАЗИЯ ЯШЬЛӘРЕ МӘЙДАНЧЫГЫ

## Муса Җәлил безнең йөрәкләрдә



Сугыш... Күпме кешенең чәчәктәй гомерен өзгән ул. Күпме гөнаһсыз кешенең каны дәрья булып аккан. Ватан өчен барган көрәштә татар халкының күпме бөек уллары башын салган. Алар арасында каһарман шагыйрь, Советлар Союзы Герое Муса Җәлил дә бар. Безгә, XXI гасырда яшәүче балаларга бу исем якын.

Әдәбият дәресләрендә без шагыйрьнең иҗаты белән танышабыз. Китапханәдән аның китапларын алып укыйбыз. Аның шигырьләре бүген дә популяр, яратып укыла. Гимназиядә шагыйрь иҗатына багышлап үткәрелгән викторина, кичәләрдә, квест-уеннарда катнашып, күп мәгълүмат туплыйбыз.

1941 нче елда фронт линиясе якынлашкач, Курск өлкәсендә урнашкан политруклар әзерләү курсларын Минзәлә шәһәренә күчерәләр. Курсантлар Бөгелмә белән Минзәлә арасын җәяүләп үтәләр. Юл безнең Мөслим аша үтә, хәрбиләр Мөслимдәге урта мәктәптә төн уздыралар. Бу вакыйга белән без бик горурланабыз, димәк 1941 елның көзендә Мөслим урамнары аша Муса Җәлил узган! Без йөргән урамнарда аның да аяк эзләре калган!

Шагыйрьнең балалар өчен язган шигырьләре белән беррәттән, "Моабит дәфтәрләре" циклыннан булган шигырьләрен дә зур бер дулкынлану белән укыйбыз. Үлем карары чыгарылгач та, шагыйрь күңелен төшерми, рухын сындырмый. Төрмәнең кысан, караңгы камерасында да аның өчен иҗат йолдызы балкый. Йөрәгеннән ургылып чыккан кичерешләре, фашистларга карата нәфрәт, ачу шигырьләренә күчә. Немецларга каршы көрәшкә ул штык белән түгел, көчле каләме белән чыга.

М.Җәлил, Моабит төрмәсендә үлем көткәндә, юмористик шигырьләр дә иҗат иткән. Баш очында палач балтасы эленеп торганда, көлкеле нәрсәләр турында уйларга, елмайтырлык шигырьләр иҗат итәргә каян көч тапты икән шагыйрь? Бу сорау миндә "Сыра залында", "Ишек төбендә", "Томаулы гашыйк" кебек кызыклы шигырьләрне укыгач туды. Уйлана торгач, мин болай нәтиҗә ясадым: бу шигырьләр караңгы төрмәне әз генә булса да яктырткандыр, үзенең һәм башка әсирләрнең күңелләрен күтәргәндер.

Үлем җәзасына хөкем ителгәч тә, шагыйрь Муса Җәлил көчле рухлы булып калган: җаны, рухы биеклеккә омтылган. М.Җәлилнең көрәштәшләре дә үзе кебек көчле рухлы булганнар. Юкка гына, алар турында "татарлар елмаеп үлделәр", дип әйтмиләр бит.

Аның кабатланмас рухы безнең йөрәкләрдә мәңге сакланыр.

***Солтанова Алия,***
***8 нче б сыйныфы укучысы***

********



## 75 ел Бөек Җиңүгә

75 ел элек илебезгә
Немец гаскәрләре ташланган.
СССРга каршы Герман иле
Игълан итми сугыш башлаган.

Чиктәш илләр беренчеләр булып,
Сугыш афәтенә эләккән.
Самолеттан төшкән бомбалар
Җимергәннәр барысын рәттән.

Җир өстеннән үткән танклар,
Шәһәрләрне камап алганнар.
Каладагы йортлар җимерелгән,
Күп авыллар дөрләп янганнар.

Дошманнарны яуда җиңү өчен,
Ир-егетләр киткән сугышка.
Хатын-кызлар балалары белән
Ләгънәт укып калган фашистка.

Яу кырында совет солдатлары
Курку белми алга барганнар.
Арысланнар кебек сугышканнар,
Яу кырында ятып калганнар.

Ничә тапкыр камалышта калып,
Ялангачлык, ачлык сынаган.
Сугыш кырларында солдатларның
Тагын бер кат көче сыналган.

Илнең тылы ныклы, көчле булу –
Тылдагылар хезмәт җимеше.
Хатын-кызлар, балаларның көче,
Ил토ткасын ныклы тотучы.

Авырлыкка түзгән илем халкы,
Җитештергән икмәк, киемнәр.
Йон бияләй, җылы оекбашлар -
"Бары фронт өчен!" – диелгән.

Еллар үткән, сугыш дәвам иткән,
Кеше гомерләре өзелгән.
Сугыш кырларында ятып калган
Герой солдатлар да,
Туган җирдән ерак күмелгән...

Сугыш беткән... Тол калганнар
Җир йөзендә күпме аналар...
"Әти" сүзен бер дә әйтәлмичә,
Ятим калган күпме балалар.

Хатын-кызлар әле һаман көтә
Яуга киткән газиз ирләрен.
Карт әбиләр көтә, әниләре көтә,
Кайтыр диеп улы-кызларын.
Бу канкойгыч сугыш афәтләрен
Истә тотар халкым, онытмас.

Чит җирләрдә ятып калганнарның
Каберенә эзне суытмас.
Искә алыйк, арабыздан китеп,
Бакыйлыкка күчкән җаннарны.

Кадерләрен белик исәннәрнең,
Хөрмәт белән карыйк.
Алар саны
Бары бармак белән санарлык...

Гөрләп чәчәк ата туган илем,
Һәр туган көн – безгә куаныч.
Илем тыныч, яшәүләре ямьле,
Тирә-ягым матур, сокланг ыч!

Җиңү бәйрәмнәре якынлаша
Көннәр тыныч булсын илемдә,
Ямьле язлар җиңү бүләк иткән илгә –
75 ел Бөек Җиңүгә!

***Лиана Хәбибуллина,***
***9 нчы б сыйныфы укучысы***

*Шигырьләр укуны дәвам итегез*

ТЫЛСЫМ+
*Февраль, 2020 нче ел*
*№4 (36)*
(2014 нче елдан
айга бер мәртәбә нәшер ителә)
*Мөслим гимназиясе укучылары газетасы*

**Баш мөхәррир:** Тимергалиева Э.В.
**Техник редактор:** Кадыйрова А.Р.
**Мөхәррир:** Нассер Мәрьям
**Корректор:** Ханнанова Алинә
**Корреспондентлар:** Бәдретдинова Әдилә, Идиятуллина Сабина
**Дизайнер:** Шәкертҗанов Илназ
**Компьютерда җыючы:** Шәйхиев Раил

**Гамәлгә куючы:**
Мөслим гимназиясе укучылар иҗат үзәге
**Адрес:** Мөслим, Кооператив урамы, 170а
**Сайт:** https://edu.tatar.ru/muslum/muslumgym
**Электрон адрес:** tilsim.gimnazia@yandex.ru
**Формат:** А3
**Тираж**: 100